**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 02.04.2020** **№ 339**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 нчы елның 30 нчы апрелендәге 592 нчы номерлы «Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексы, 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законы, 2019 елның 25 декабрендәге 106-ТРЗ номерлы «Тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин кертү электрон системаларын балигъ булмаганнарга сатуны тыю турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» 2019 елның 30 апрелендәге 592 номерлы карары белән билгеләнгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә (2019 нчы елның 23 нче сентябрендәге 1617 нче номерлы карары редакциясендә ) түбәндәге эчтәлектәге 28 нче пунктны өстәп үзгәрешләр кертергә:

| № | Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексы (алга таба- АХБт ТРК) | Вазыйфаи затлар исемлеге |
|---|---|---|
| 28 | АХБт ТРК 2.16 статья<br>Тәмәкесез никотинлы продукцияне, никотин кертү электрон системаларын балигъ булмаганнарга сатуны тыюны | - «Административ-техник инспекция» МКУсе начальнигы<br>- «Административ-техник инспекция» МКУсе баш белгече |

| | | |
|---|---|---|
| | бозу, шулай ук балигъ булмаганнарны тәмәкесез никотинлы продукцияне куллануга тарту | - "Административ-техник инспекция" МКУсе әйдәп баручы белгече |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.П. Афанасьевка йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин